ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 210

2020-2021 елларга Кайбыч муниципаль районы буенча бюджет чыгымнарын оптимизацияләү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планын раслау турында

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020-2021 елларга Кайбыч муниципаль районы буенча бюджет чыгымнарын оптимизацияләү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планын (1 нче кушымта) расларга.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә, чараларны җаваплы башкаручыларга тәкъдим итәргә:

2.1. муниципаль программаларны тормышка ашырганда, шулай ук Кайбыч муниципаль районының норматив хокукый актлары проектларын әзерләгәндә план нигезендә эш итәргә;

2.2. 2020 елның 1 маеннан башлап, хисап чорыннан соң килүче һәр айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, Кайбыч муниципаль районы Финанс- бюджет палатасына Кайбыч муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимизацияләү буенча чаралар планын үтәү турында хисаплар җибәрергә.

2.3. әлеге карарны муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Заһидуллин Э.Х.га йөкләргә.

Җитәкче А. Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.04.2020
210
номерлы карарына 1 нче кушымта

Бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, Кайбыч муниципаль районы буенча өстәмә бюджеттан тыш чыганаклар эзләү буенча
чаралар планы

| | **чараның исеме** | **тормышка ашыру срогы** | **финанс бәясе - мең сум** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел |
| **1.** | **Салым һәм салым булмаган керемнәрне арттыру буенча чаралар** | | **2 300,0** | **249,0** |
| 1.1. | Салым һәм җыемнарны өстәмә мобилизацияләү, шул исәптән салым базасын киңәйтү хисабына | 2020-2021 | 0,0 | 33,0 |
| 1.2. | Күләгәдә мәшгульлекне легальләштерү буенча чаралар үткәрү | 2020-2021 | 200,0 | 100,0 |
| 1.3. | Салым булмаган керемнәр күләмен арттыру, шул исәптән муниципаль берәмлекләр милкенә арендага бирелә торган мөлкәт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвенең нәтиҗәле ставкаларын билгеләү чараларын үткәрү исәбенә дә. Муниципаль милектәге мөлкәтне инвентаризацияләүне дәвам итәргә:<br>- муниципаль милекне тоталь исәпкә алуны гамәлгә кертү - файдаланылмаган (хуҗасыз) мөлкәтне ачыклау һәм аны нәтиҗәле файдалану юнәлешләрен билгеләү;<br>- аренда түләве яки вакытлыча файдалануга тапшырган өчен башка түләү рәвешендә алына торган | 2020-2021 | 500 | 100,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | керемнәрне арттыру максатыннан арендага бирелә торган мөлкәтнең исемлеген билгеләү һәм раслау;<br>- муниципаль учреждениеләрнең файдаланылмый торган төп фондларын ачыклау һәм аларны сату яки арендага бирү буенча тиешле чаралар күрү. | | | |
| 1.4. | Физик затларның милек салымнарын мобилизацияләү буенча чаралар үткәрү. | 2020-2021 | 0,0 | 16,0 |
| 1.5. | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны киметү буенча чаралар үткәрү. | 2020-2021 | 1 600,0 | 0,0 |
| **2.** | **Чыгымнарны оптимальләштерү чаралары** | | **0,0** | **20,0** |
| **2.1.** | **Муниципаль хезмәт** | | **0** | **20** |
| 2.1.1. | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру максатларында муниципаль милектәге мөлкәтне файдалану нәтиҗәлелеген арттыру | 2020-2021 | 0,0 | 20,0 |
| **2.2.** | **Бюджет челтәрен оптимальләштерү** | | **2 588,0** | **131,0** |
| 2.2.1. | «Вак» учреждениеләрне, шулай ук 50% тан кимрәк йөкләнгән оешмаларны эреләндерү яки кушу | 2020-2021 | 1 488,0 | 0,0 |
| | шул исәптән Шүширмә башлангыч мәктәбен Борындык урта мәктәбенә кушу | 2020-2021 | 296,0 | 0,0 |
| | Надеждино төп гомуми белем бирү мәктәбен башлангыч мәктәп итеп үзгәртеп кору | 2020-2021 | 1 192,0 | 0,0 |
| 2.2.2. | Учреждениеләрнең артык мөлкәтен реализацияләү (сату), консервацияләү - кулланылмый торган мөлкәтен сату | 2020-2021 | 1 100,0 | 131,0 |
| | шул исәптән җәйге чорда балалар бакчалары эшен туктатып торудан экономия | 2020-2021 | 1 100,0 | 0,0 |
| | Плетени авыл клубы консервациясе | 2020-2021 | 0,0 | 131,0 |
| **2.3.** | **Инвестиция чыгымнарын, юридик затларга субсидияләрне һәм дебитор бурычларын оптимальләштерү** | | **200,0** | **0,0** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.3.1. | Дебитор бурычлары барлыкка килү сәбәпләрен анализлау һәм аларны киметү планын кабул итү | 2020-2021 | 200,0 | 0,0 |